**«Мин яратам сине, туган авылым!»**

Максатлар: 1. Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү;

2. Иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү;

3. Фонетик кагыйдәләрен ныгыту;

4. Туган илгә, Туган авылга мәхәббәт тәрбияләү.

Дәрес барышы:

- Исәнмесез, утырыгыз. Хәзер без кечкенә генә клип карап үтәрбез, аннан соң бергә дәресебезнең темасын билгеләрбез.(Клип карау)

Сез тыңлаган җыр һәм караган видеофилм нәрсә турында? Дөрес, җыр да, клип та Туган ил, туган авыл турында. Димәк, бүген дәрестә без туган ил, туган авыл турында сөйләшербез.(Максат.)

Сез бүген ике төркемгә бүленеп эшләрсез. Беренче төркемдә Азиз, Дамир, Илүзә, Динә, икенчесендә Резеда, Рамил, Фанис, Алмир.

Бүгенге дәрестә сезнең өчен аңлашылмаган яңа сүзләр булыр. Шуның өчен сүзлекләр эшләнде. Әйдәгез, бу сүзләр белән танышып үтик.(Сүзлекләр)

**Ә хәзер беренче бирем**. Тактада дәресебезнең темасы язылган, тик аны чишәргә кирәк. ("Мин яратам сине, туган авылым!" дигән тема . Дәфтәрләргә число, сыйныф эше һәм темасы языла.)

Димәк, без бүген Туган илебез, туган авылыбыз турында иншa язарга әзерләнербез.Ә сезнең өчен Туган ил – нәрсә ул? Нәрсәдән башлана ул? Сез ни өчен туган җирне яратасыз?

Шулай итеп, Туган ил – ул әти-әни өе, туган авыл, кырлар, урманнар...сез монда туып-үстегез, туганнарыгыз, дус-ишләрегез монда яши. Ә авылыбыз турында сез нәрсә беләсез? Хәзер Кистем авылы тарихы турында музей җитәкчесе Илмир абыегыз сөйләп үтәр. (Кистем тарихы). Сорауларыгыз булса, соңыннан бирерсез.

**Икенче бирем**. Туган ил, туган авыл турында сез нинди шигырьләр беләсез? ( Илүзә, Рамил, Резида) Рәхмәт, сез күп кенә шигырьләр беләсез икән. Ә бу шигырьләрдә нәрсә турында сөйләнә? Туган ил нинди итеп күз алдына килә? Дөрес, боларда туган җирнең матурлыгы, искиткеч бай табигате, киң күңелле кешеләре турында сүз бара. Безнең авылыбыз, аның сөйләп бетермәслек бай табигате, гүзәл кызлары, батыр егетләре турында да язылган шигырь бар. Аның язучысы да безнең авылдашыбыз – Насыйбулла Кадырович Касимов.( Шагыйрь турында сөйләү)(Динә)

Туган ил, туган җир турында бик күп әсәрләр язылган. Бу темага язмаган шагыйр, язучы юктыр. Чөнки һәр кеше Туган илен, туган җирен өзелеп ярата. Мәсәлән, Г. Бәшировның " Туган ягым – яшел бишек" повестен алыйк. Бу әсәрдә язучы үзенең туган ягының матур табигатен, туган авылындагы милли бәйрәмнәр, йолаларын искиткеч матур итеп тасвирлый.

Ә менә Г. Кутуйның "Сагыну" исемле әсәрендә туган җирне сагыну хисе тасвирлана. Чит илдә, сугыш кырында йөргән солдатның туган илен, әти-әнисен сагынуы, яратуы, аларны тизрәк күрәсе килүе сурәтләнә. ( "Сагыну" нәсереннән өзек тыңлау)

**Физкультминутка.**

**Өченче бирем.** Әйдәгез, туган авылыбыз турында кечкенә генә шигыр языйк. Шигыребезнең соңгы сүзләре бирелгән инде.

...Кистемем.

... яратам.

... киләчәгең,

... ата-анам.

Ә хәзер килеп чыккан шигырьләрне укып чыгыгыз.(Азиз, Фанис)

**Дүртенче бирем**. Сезнең алдыгызда карточкаларда шигырдән өзек китерелгән. Анда күпнокталар урынына тиешле хәрефләрне куярга кирәк. (эшләү). Әйдәгез, шигырне тикшерәбез. (Алмир,Дамир)

**Бишенче бирем.** Һәр төбәк, һәр район нинди дер урыннары, күренекле шәхесләре белән горурлана. Ә безнең авылда шундый урыннар, кешеләр бармы? (Ахмаров, Җәмилә)

**Алтынчы бирем**. Тагын бер бирем. Кистем авылының киләчәген ничек итеп күз алдына китерәсез?

**Гомумиләштерү.** Бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барды? Сез авылыбыз турында нәрсәләр белдегез?(Җаваплар)

Инша язганда нәрсә турында язарсыз?

Ә хәзер һәрберегез дәрестә ничек катнашканыгызга карап бер-берегезгә бәя куегыз. Бу бәяләр белән килешәсезме?

**Өй эше.** "Мин яратам сине, туган авылым!" дигән темага инша язарга.